**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**25 февраль 2025 ел** **№ 126**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы

**Карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун ел срокка расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын һәм аның график сурәтен дә кертеп, 26.02.2025 дан да соңга калмый, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару, шулай ук, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стенденда урнаштыру юлы белән белән халыкка җиткерергә. Шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын «Биектау хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга.

3. Карар ул басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина

Кушымта
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы
25.02.2025 № 126 карарына

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы**

1 нче бермандатлы сайлау округы. Сайлаучылар саны - 58.
Округка Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Алан-Бәксәр авылы - Үзәк урам, 1-38 йортлар; Яшел урам, 1-9 йортлар; Кызыл Тау урамы, 1-6 йортлар; Комлы урам, 1,3,5,7,9,11,13 йортлар.

2 нче бермандатлы сайлау округы. Сайлаучылар саны - 59.
Округка Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Алан-Бәксәр авылы - Яңа урам, 1-20 йортлар; Комлы урам – 2,4,6,8,10,12 йортлар.

3 нче бермандатлы сайлау округы. Сайлаучылар саны - 55.
Округка Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Алан-Бәксәр авылы - Гагарин урамы, 1- 29 йортлар; Әсән авылы - С.Сәйдәшев урамы, 1 -16 йортлар; Ш.Усманов урамы - 1- 3 йортлар; Алат спиртзаводы авылы - Үзәк урам, 1 – 33 йортлар; Урман урамы, 1, 2 йортлар; Яшьләр урамы, 8, 10, 11, 11а йортлары.


4 нче бермандатлы сайлау округы. Сайлаучылар саны - 55.
Округка Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Алан-Бәксәр авылы - Татарстан урамы, 1-14 йортлар; Мәктәп урамы, 1-12 йортлар; Үзәк урам, 39 - 47 йортлар.

5 нче бермандатлы сайлау округы. Сайлаучылар саны - 54.
Округка Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Алат спиртзаводы авылы - Яшьләр урамы, 1 – 6 йортлар; Завод урамы, 1 – 27 йортлар; Болын урамы, 1-11 йортлар; Үзәк урамы, 34 – 74 йортлар.

6 нчы бермандатлы сайлау округы. Сайлаучылар саны - 58.
Округка Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Гәр авылы - Үзәк урам, 1 - 31 йортлар; Урман урамы, 1 - 8 йортлар; Светлогорье территориясе, 10 йорт.

7 нче бермандатлы сайлау округы. Сайлаучылар саны-52.

Округка Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Гәр авылы - Мәктәп урамы, 2-10 йортлар; Үзәк урамы, 32 - 95 йортлар; Шөмлән авылы - Үзәк урамы, 1 - 27 йортлар.


УИК-1290
ДЕЖУРНО-КАДАСТРОВАЯ КАРТА
Н.П. АЛАН БЕКСЕРЬ
АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СМСУ
16 16 02 01 01
Округ №4
с. Алатский спиртзавод
Округ №5
Округ №3
с. Алан-Бексер
Округ №3
Д. Асянь
Округ №1
Округ №2

УИК - 1291

